| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |

| | |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| 26.02.2021 | № 116-пр |

Казан ш.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль закон, «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге №112 Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурслар үткәрүнең һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертүнең бердәм методикасын раслау турында” 2018 елның 31 мартындагы № 397 карары һәм “Татарстан Республикасы гражданлык хезмәте турында” 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында тәкъдим ителгән нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгене билгеләргә::

Министрлыкның конкурс һәм (яки) аттестация комиссиясе составында өч елдан артык торган бәйсез экспертлар үз вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклыйлар;

Министрлыкның конкурс һәм (яки) аттестация комиссиясе составында 2021 елның 1 гыйнварыннан санаганда өч елдан азрак булучы бәйсез экспертлар үз вәкаләтләрен Министрлыкның әлеге комиссиясе составына кертелгәннән соң өч ел дәвамында саклыйлар.

3. Министрлыкның түбәндәге боерыклары өчен югалткан дип таныргa:

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» 06.03.2017 № 86-пр боерыгы;

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 6 мартындагы № 86-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 13.10.2017 № 504-пр боерыгы;

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 6 мартындагы № 86-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 27.06.2018 № 318-пр;

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 6 мартындагы № 86-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс

үткәрү турында нигезләмәнең 3 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында” 05.10.2018 № 498-пр.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
26.02.2021 №116-пр
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелү) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелү) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

1.2. Министрлыкта Конкурс «Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба - Федераль закон) һәм «Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, “Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында” 1 февраль, 2005 ел, 112 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурслар үткәрүнең һәм дәүләт органнары кадрлар резервына кертүнең бердәм методикасын раслау турында” 2018 елның 31 мартындагы № 397 карарына, “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар эшендә мәгълүмати технологияләр кертүнең кайбер чаралары турында” 2018 елның 5 мартындагы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, “Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау турында” 2011 елның 14 мартындагы УП-127 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указына, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарга тест үткәрүне оештыру мәсьәләләре” 2015 елның 11 декабрендәге № УП-1192

Татарстан Республикасы Президенты Указына туры китереп үткәрелә.

Конкурс Министрлыкта гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасына (алга таба – гражданлык хезмәте) дәгъва итүчеләрнең һөнәри дәрәҗәсен, аларның бу вазыйфа өчен квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс, Федераль законнар буенча конкурс нигезендә биләнә торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булган очракта, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (аның вазыйфаларын башкаручы затлар) (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

Вакантлы вазыйфаны биләү өчен конкурс кадрлар бүлеге тарафыннан оештырыла.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның кадрлар бүлеге тарафыннан Министрлыкның гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфаларын биләүдә белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗ ихтималыннан чыгып һәм Министрлыкта булган кадрлар резервын ел саен барлау нәтиҗәләре буенча оештырыла. Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс министр карары белән игълан ителә.

1.5. Вакантлы вазыйфаны биләү өчен конкурс (кадрлар резервына кертелүгә конкурс) Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.6. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган "җитәкчеләр" һәм "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категориясендәге гражданлык хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм $60^1$ статьясының 9 өлешендә каралган очракларда гражданлык хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

гражданлык хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.7. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча билгеләгәндә;

министр карары буенча, гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә карый торган гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә гражданлык хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел

хокукларын, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.9. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатларга алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны профессиональ әһәмияткә ия объектив критерийләр нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

1.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерә ала.

1.11. Гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва итеп, конкурска үткәрелмәүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч ел дәвамында язмача гариза буенча кайтарыла ала. Әлеге срокта документлар Министрлык архивында саклана, соңрак алар юкка чыгарыла. Конкурста катнашу өчен электрон форматта тапшырылган документлар да өч ел саклана, соңрак алар бетерелә.

1.12. Конкурска катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга килү һәм кайтып китү, яшәү урыны арендалау, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз хисабыннан тотыла.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

2.1. Министрлыкта конкурсны үткәрү өчен Министрлык боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе эшенең объективлыгын һәм бәйсезлеген арттыру һәм гражданлык хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен конкурсларны нәтиҗәле оештыру максатларында министрлык карары белән аның составы даими алыштырылып тора. Комиссия составы министр боерыгы белән раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән комиссия рәисе җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясенең сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яисә) аның вәкаләтле граждан хезмәткәрләре (шул исәптән, кадрлар бүлегеннән һәм гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәдән (кадрлар резервына кертү өчен конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте төркемнәре буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган бүлекчәләр), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – законнарда билгеләнгән тәртиптә Министрлык запросы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан гражданлык хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр рәвешендә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм бүтән оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан арта алмый.

Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрелгәндә конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.6. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе кандидат белән шәхси әңгәмә үткәрмичә торып конкурс җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итә алмый.

Конкурс комиссиясе аның әгъзасының яки кандидатның сәбәбе (нигезләре) күрсәтелгән тәкъдиме буенча утырышны видеоконференция форматында үткәрү (техник мөмкинлекләр булса) турында карар кабул итә ала.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында чыгарыла.

2.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелеге тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисенең тавышы

хәлиткеч булып тора.

2.11. Комиссиясенең гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс буенча тавыш бирү нәтиҗәләре, конкурс комиссиясе карары буларак, әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелгән формада рәсмиләштерелә. Комиссиясенең кадрлар резервына кертелүгә конкурс буенча тавыш бирү нәтиҗәләре, конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе буларак, әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында китерелгән формада рәсмиләштерелә.

Әлеге карар һәм беркетмә кандидатларның җыйган баллары һәм конкурс комиссиясе бәясе нәтиҗәләре буенча алган урыннары күрсәтелгән рейтингны үз эченә ала.

2.12. Конкурсны һәм конкурс комиссиясенең эшен оештыру һәм үткәрүне тәэмин итүне Министрлыкның кадрлар бүлеге тормышка ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатларга карата таләпләргә җавап бирә торган һәм шушы Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган вакыт эчендә шушы Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган гражданнар конкурста катнашуга кертелә.

3.2. Граждан (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазифалары) квалификацион таләпләргә туры килмәү сәбәпле, шулай ук, федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр булганда конкурста катнашырга кертелми.

3.3. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларга таләпләр Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Россия Федерациясенең конкурста катнашырга теләк белдергән гражданы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

а) әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча шәхси гариза;

б) Россия Федерациясе Хөкүмәте расланган формада үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотосын теркәп;

в) паспортның яки аны алмаштыра торган документның (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә) күчермәсе;

кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яктан яки хезмәт итү (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе һәм (яки) эшчәнлек турында Россия Федерациясе законнары билгеләгән тәртиптә формалаштырылган белешмәләр һәм (яки) гражданның эшкә бәйле (хезмәт)

эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклар искәрмә булып тора);

белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, үз ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүне раслый торган документларның, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

гражданда гражданлык хезмәтенә керүгә яки аны үтүгә комачаулый торган чирләрнең булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган 001-ГС/у исәп формасы);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3.5. Конкурста катнашу теләген белдергән Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфасын башкарган гражданлык хезмәткәре гаризасын бары тик министр исеменә яза.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә язылган шәхси гариза һәм үз куллары белән тутырылган, имзаланган һәм граждан хезмәткәре гражданлык хезмәте вазыйфасын үтә торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкета тапшыра, фотосын теркәп.

3.6. Гражданның (гражданлык хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә граждан (гражданлык хезмәткәре) биләүгә дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны башкару мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан министр исеменә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиешле. Электрон форматта бирелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылып тикшерелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документларны Министрлыкка конкурсны үткәрү турында мәгълүмати хәбәр “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүче бердәм мәгълүмат системасы” федераль дәүләт мәгълүмати системасының рәсми сайтында (алга таба – Федераль мәгълүмати система) урнаштырылганнан соң 21 көн эчендә граждан (граждан хезмәткәре) шәхсән үзе, почта аша юллап яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә

Федераль мәгълүмати системаны кулланып электрон рәвештә тапшыра.

Документларны җитди сәбәпләрсез генә үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан (гражданлык хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыруның җитди сәбәпләре булса, министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы

## IV. Конкурс үткәрү методикасы

4.1. Конкурслар үткәрүгә әзерлек кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымларына таянуны (алга таба – бәяләү алымнары) һәм шуңа туры килә торган конкурс биремнәре һәм процедуралары куллануны, ихтыяҗ булганда конкурс үткәрү планлаштырылган гражданлык хезмәткәре вакантлы вазыйфасына карата гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары кагыйдәләрен актуальләштерүне үз эченә ала.

4.2. Гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары кагыйдәләрен актуальләштерү, бәяләү алымнарын сайлау һәм аларга туры килгән конкурс биремнәрен сайлау Министрлыкның кызыксынган бүлекчәсе тарафыннан кадрлар бүлеге белән килешеп формалаштырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү алымнары куллану һәм конкурс биремнәре фолрмалаштыру турында үз тәкъдимнәрен кертә ала.

Гражданлык хезмәткәрләренең вакантлы вазыйфаларына мөнәсәбәтле министр карары буенча гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламантларында конкрет белгечлеккә (әзерлек юнәлеше) квалификацион таләпләр куела ала.

4.3. Конкурс барышында кандидатларның профессиональ дәрәҗәсен, аларның квалификацион таләпләргә туры килүен бәяләү өчен федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән бәяләү алымнары кулланыла ала, боларга гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервы әзерләнгән гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме) вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйлк индивидуаль әңгәмәләр, анкета, төркем белән дискуссияләр, документ проекты әзерләү, реферат һәм язу башка язмача эшләр, практик биремнәр чишү яки сораулар буенча тестлар уздыру

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.5. Беренче этапта кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурсны үткәрү турында мәгълүмат әзерләп, аны Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларына урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала: гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасының)

аталышы, бу вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре, гражданлык хезмәтен үтү шартлары, дәүләт гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен документлар исемлегенә туры китереп кандидатлар Министрлыкка тапшырырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү срогы, конкурсны үткәрүнең күзалланган вакыты, аның үткәрелү урыны һәм тәртибе, бәяләү алымнары турында белешмәләр, вазыйфат бурычларын, хокукларын һәм башкармау очрагында (тишенчә башкармау) җаваплылыкны да кертеп, гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи регламенты кагыйдәләре, гражданлык хезмәткәре эшчәнлегенең һөнәри эш нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, якынча квалификация тестына Федераль мәгълүмат системасына урнаштырылган сылтама, башка мәгълүмати материаллар.

кандидатлар тапшырган документларны тикшерә;

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (бүтән төрле гражданлык хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.6. Дәгъва итүче үзенең һөнәри дәрәҗәсен үзлегеннән бәяләп карау өчен конкурс кысаларыннан тыш конкурс белдерүендә күрсәтелгән якынча квалификация тестын уза ала.

Якынча тест дәгъва итүчеләрнең Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, Россия Федерациясенең дәүләт хезмәте һәм коррупциягә каршы тору турындагы законнарын белүне, мәгълүмати коммуникацияләр технологияләре өлкәсендәге күнекмәләрен бәяләү буенча биремнәрне үз эченә ала.

Якынча тест Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтына урнаштырыла, дәгъва итүчеләргә аны түләүсез үтү мөмкинлеге тудырыла.

Конкурс комиссиясе дәгъва итүчеләрнең якынча тест узу нәтиҗәләренә игътибар итми һәм алар конкурста катнашу өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

4.7. Тикшерү барышында федераль законнар, Россия Федерациясенең федераль законнары һәм бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның гражданлык хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа министр тарафыннан конкурста катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында язмача хәбәр ителә. Граждан конкурста катнашу өчен документларын электрон форматта тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту турында белдерү Федераль мәгълүмати системаны кулланып, көчәйтелгән квалифицикацияләнгән электрон имза куелып, электрон документ формасында җибәрелә.

4.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән, Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.9. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булуы конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яки вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурс комиссиясе тарафыннан конкурсның узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.10. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, министр конкурсның икенче этабын үткәрү датасы (катнашу өчен документлар кабул ителү тәмамлангач, 30 календарь көненнән дә соңармыйча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуга рөхсәт әзерләргә кирәк булган очракта икенче этапны үткәрү вакытын министр билгели.

Министрлыкның кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көннән дә соңга калмыйча Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларына үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашырга үткәрелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра, кандидатларга әлеге хәбәрне язмача да юллый, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвешендә тапшыручы кандадитларга - Федераль мәгълүмат системасын кулланып, көчәйтелгән квалификацияләнгән электрон имза куелган электрон документ рәвешендә.

4.11. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

кандидатлар турында мәгълүматны “Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте кадрлар составы һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт бердәм мәгълүмати системасы” Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Бердәм мәгълүмати кадрлар системасы) кертә;

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

Министрлыкта гражданлык хезмәте вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе карарын кабул итү;

конкурс нәтиҗәләрен Бердәм мәгълүмати кадрлар системасында рәсмиләштерә;

конкурс нәтиҗәләрен Министрлык һәм Федераль мәгълүмат системасы

сайтларына урнаштыру.

4.12. Конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны белеме, гражданлык хезмәтен яки бүтән дәүләт хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук, тестлар, анкеталар, шәхси әңгәмәләр уздыру, реферат яки башка язма эшләр яздыру, документ проекты әзерләтү ысулларын үз эченә алган конкурс процедуралары нигезендә бәяли. Конкурс үткәрелгән вазифаларның төркеменә һәм категориясенә карап, төрле ысуллар кулланыла ала. Шул ук вакытта тест уздыру һәм кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр бөтен кандидатлар өчен мәҗбүри санала.

